РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН
АТНИНСКИЙ РАЙОННЫЙ
ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ

422750, село Большая Атня,
улица Советская, дом 38

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ӘТНӘ РАЙОНЫНЫҢ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

422750, Олы Әтнә авылы,
Совет урамы,38нче йорт

Тел./факс: 8(84369)21020, E-mail: atnya@tatar.ru, сайт: atnya.tatarstan.ru

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

13 сентябрь 2024ел. № 412

**Әтнә районы башкарма комитетының 2021 елның 06 августындагы 259 номерлы “Сәүдәләрдә җир кишәрлеген арендага, милеккә бирү буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламентын раслау турында”гы карарына үзгәрешләр кертү хакында**

“Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүне оештыру турында” 2010 елның 27 июлендәге 210-ФЗ номерлы Федераль законны гамәлгә ашыру максатларында, “Россия Федерациясе Шәһәр төзелеше кодексына һәм Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү турында” 25.12.2023 № 627-ФЗ Федераль законга таянып, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының “Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте башкарма органнары тарафыннан дәүләт хезмәтләре күрсәтүнең административ регламентларын эшләү һәм раслау тәртибен раслау турында һәм Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының аерым карарларының үз көчләрен югалтуын тану хакында” 28.02.2022 елның 175 номерлы карары белән, Әтнә районы башкарма комитеты карар итә:

1.Әтнә районы башкарма комитетының 2021 елның 06 августындагы 259 номерлы “Сәүдәләрдә җир кишәрлеген арендага, милеккә бирү буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламентын раслау турында”гы карарына түбәндәге үзгәрешләрне һәм өстәмәләрне кертергә:

1.1. карарның преамбуласында “Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте башкарма органнары тарафыннан дәүләт хезмәтләрен күрсәтүнең административ регламентларын эшләү һәм раслау тәртибен раслау һәм Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының аерым карарларына үзгәрешләр кертү турында” 2010 елның 2 ноябрендәге 880 номерлы Татарстан Республикасы Министрлар кабинеты карары белән” сүзләрен “Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте башкарма органнары тарафыннан дәүләт хезмәтләрен күрсәтүнең административ регламентларын эшләү һәм раслау тәртибен раслау һәм Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының аерым карарларының үз көчләрен югалтуын тану турында” 28.02.2022 № 175 Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты карары белән” сүзләре белән алыштырырга;

1.2. Административ регламентның 2.8.2.1 пунктының 13 пунктчасына “яисә территорияне комплексны үстерү турында Карар кабул ителде, аны гамәлгә ашыру Россия Федерациясе Шәһәр төзелеше кодексы нигезендә Россия

Федерациясе яисә Россия Федерациясе субъекты билгеләгән юридик зат тарафыннан тәэмин ителә” сүзләрен өстәргә.

2. Әлеге карарны Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге рәсми хокукый мәгълүмат порталында (https://pravo.tatarstan.ru) һәм Татарстан Республикасы Әтнә муниципаль районының рәсми сайтында (https://atnya.tatarstan.ru) бастырып чыгарырга.

3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үземдә калдырам.

Җитәкче А.Ф. Каюмов